КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 июль г.Казань № 666

Казан шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2022» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2022 елның 9 июлендә 12 сәгать 00 минуттан 16 сәгать 30 минутка кадәр «SVIYAGA FEST – 2022» гаилә фестивален үткәрү чорында Свияга елгасы һәм Свияжск утрау-шәһәре тирәли яр буеннан 600 метр ераклыкта Идел елгасы участогында азсыешлы, ял итү, җилкәнле спорт судноларын файдалануны тыярга;

2022 елның 6 августында 12 сәгать 00 минуттан 20 сәгать 00 минутка кадәр «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәрү чорында Казансу елгасы участогында, Кремль дамбасыннан «Миллениум» күперенә кадәр, азсыешлы, ял итү, җилкәнле спорт судноларын файдалануны тыярга;

бу пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю «SVIYAGA FEST – 2022» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне

сайлыйм» авиация бәйрәмен әзерләүгә һәм үткәрүгә җәлеп ителгән судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карарның 1 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән тыюны үтәү максатларында әлеге участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә бу карарның 1 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин